Лешев-Тамакское сельское поселение Сармановского муниципального района

Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**24.06.2024ел.**

**КАРАР**
**№9**

**«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрен акчалата карау турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте узучы (узган) затларны бер мәртәбә бүләкләү турында» 2023 елның 17 гыйнварындагы ПУ-31 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә һәм «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 5 өлеше һәм 31 статьясындагы 2 өлеше, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, аудиторларының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнарының депутатларның, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы карары нигезендә Ләшәү Тамак авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең акчалата эчтәлеге турында» 2018 елның 13 августындагы 11 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Карарның 1 нче кушымтаның 2 пунктында «12 688» санын «13 323» саннарына алмаштырырга;

2) Карарның 3 нче кушымтаның 6 пунктында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга;

3) Карарның 7 нче кушымтада «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга.

7. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә әлеге карарны игълан итәргә.

4. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Ләшәү Тамак авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе И.З.Хабибуллин